Каралды
Методик берләшмә җитәкчесе
______ Рамазанова Р.Н.
Беркетмә № 1
25 нче август 2017 нче ел

Килешенде
Уку-укыту эшләре буенча
директор урынбасары
______ Г.Т.Исмагилова
28 нче август 2017 нче ел

Раслыйм
Мәктәп директоры
________ Г.Т. Сабирҗанова
Приказ № 71
28 нче август 2017 нче ел

**Татарстан Республикасы**
**Сарман муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе**
**“Сарман урта гомуми белем бирү мәктәбе” татар теле һәм әдәбияты укытучысы**
**Хәмәтҗанова Фәнүзә Сәгыйрь кызының**
**6 нчы А сыйныфы өчен татар теленнән**

# ЭШ ПРОГРАММАСЫ

**Педсовет утырышында каралды**

**Беркетмә №1 28 нче август 2017 нче ел**

**2017-2018 нче уку елы**

***Сыйныф:*** *6*

***Укытучы:*** *Хәмәтҗанова Фәнүзә Сәгыйрь кызы*

*6 нчы сыйныфта ФДББС ның базис укыту планы буенча татар теле укытуга сәгатьләр саны түбәндәгечә каралган: атнага 4 сәгать. Барысы 140 сәгать.*

***Дәреслек:*** *6 нчы сыйныф өчен Ф.Ю.Юсупов, Ч.М.Харисова, Р.Р.Сәйфетдинов;-Казан:Татар.кит.нәшр.,2014. Татарстанның Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән дәреслеккә нигезләнеп төзелде.*

## I. АҢЛАТМА ЯЗУЫ

**6 нчы сыйныф өчен** татар теленнән эш программасы Россия Федерациясендәге һәм Татарстан Республикасындагы мәгарифкә кагылышлы хокукый-норматив актларга һәм федераль дәүләт стандартларына нигезләнеп төзелде.

1. Россия Федерациясенең “Мәгариф турында”гы Законы (Федеральный закон от 29.12.2012 273-ФЗ “06 образовании в Российской Федерации”);

2. Татарстан Республикасының “Мәгариф турында”гы Законы (Закон Республики Татарстан “06 образовании” № 68-ЗРТ от 22 июля 2013 года, статья 8);

3 Россия Федерациясенең “Россия Федерациясе халыклары телләре турында”гы 126-ФЗ нчы номерлы Законы (24.07.1998);

4. РФ Мәгариф һәм фән министрлыгы приказы, 30 нчы август, 2013 нче ел №115 (“Об утверждении Порядка организации и осуществления образовательной деятельности по основным общеобразовательным программам - начального общего, основного общего и среднего общего образования”);

5. “Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында” Татарстан Республикасы Законы, 2004 нче ел, 1нче июль;

6. “2014-2020 нче елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасы”, 2013 нче ел, 25 нче октябрь, 794 нче карар;

7. Төп гомуми белем бирүнең Федераль дәүләт белем бирү стандарты (Россия Мәгариф һәм фән министрлыгында 2010 нчы елның 17 нче декабрь боерыгы 1897 нче номер белән расланган, РФ Юстиция Министрлыгында 19644 нче регистрацион номеры белән 2011 нче елның 1 нче февралендә теркәлгән);

8. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы “Сарман урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомумбелем бирү учреждениесенең 2017-2018 нче уку елына укыту планы.

9. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы “Сарман урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомумбелем бирү учреждениесенең 2017-2018 нче уку елына укыту программасы.

10. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы “Сарман урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомумбелем бирү учреждениесенең “Эш программаларын төзү һәм раслау тәртибе турында” локаль акты.

6 нчы сыйныф өчен "Татар теле" курсының эш программасы Федераль дәүләт белем бирү стандартларының таләпләренә туры китереп, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм Фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән “Татар телендә гомуми төп һәм урта белем бирү мәктәпләре өчен ана теленнән программа (5 - 9 нчы сыйныфлар), төзүче-авторлары:Г.Р.Галиуллина, М.М. Шәкүрова) - Казан, 2013, 6 нчы сыйныф өчен Ч.М.Харисова, Ф.Ю.Юсупов, Сәйфетдинов Р.Р. тарафыннан төзелгән (Казан: Татарстан китап нәшрияты 2014), Татарстанның Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән уку әсбабына нигезләнеп төзелде.

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы “Сарман урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомумбелем бирү учреждениесенең 2017-2018 нче уку елына укыту планы буенча 6 нчы сыйныф татар теле дәресләренә атнага 4 сәгать бирелә, 35 атна, ел

буена 140 сәгать .

**Гомуми төп белем бирү мәктәбенең 6 нчы сыйныфында ана теленнән белем бирүнең максатлары**

1) ***коммуникатив максат***: укучыларны ана телендә иркен сөйләшергә һәм аралашырга, логик эзлекле итеп уйлый белергә, фикерне төгәл, ачык итеп җиткерә белергә өйрәтү; туган телнең аралашуда, рухи-әхлакый нормалар формалашуда һәм дөньяны танып белүдә төп чара булуын, аның эстетик кыйммәтен аңлату;

2) ***фәнни максат*:** татар теленең фонетик, график, орфографик, орфоэпик, лексик, сүз төзелеше һәм ясалышы, грамматик, стилистик нигезләре турында теоретик мәгълүмат бирү;

3) ***тәрбияви максат*:** туган телгә ихтирам һәм ярату хисләре тәрбияләү; укучыларда гуманлылык хисләрен тәрбияләү; әти-әниләргә, инвалидларга, ятим балаларга шәфкатьлелек хисләрен тәрбияләү; матурлыкны күрә, тоя белергә өйрәтү; туган як табигатен яратырга өйрәтү; туган илең белән горурлану, аны саклау; сәламәт яшәүнең бер төре булган спорт белән кызыксындыру һ.б.

**Әлеге максатларны тормышка ашыру өчен куелган бурычлар**

●укучыларның башлангыч мәктәптә татар теленең фонетик, график, орфографик, орфоэпик, лексик, сүз ясалыш, грамматик, стилистик нигезләреннән алган белемнәрен системалаштыру, катлаулырак формаларда өйрәтүне дәвам итү һәм телне тулы бер система буларак күзаллауны булдыру;

●укучыларның иҗади һәм мөстәкыйль фикерли алу мөмкинлекләрен үстерү, үз фикерләрен дәлилләргә күнектерү;

●телнең төп грамматик чараларын сөйләм процессында куллануга ирешү;

● язма һәм сөйләмә тел чараларын дөрес куллана белергә, аларны чагыштыра һәм кирәклесен сайлый, бәяли белергә өйрәтү;

●татар әдәби теле нормаларын һәм стилистик мөмкинлекләрен ачык күзаллауга, аларны тиешенчә куллана белүгә өйрәтү;

●телнең милли мәдәниятнең чагылышы булуын, тел һәм тарих бердәмлеген аңлату; татар теленең милли-мәдәни үзенчәлегенә төшендерү; татар һәм башка халыкларның рухи мирасына ихтирам тәрбияләү;

●татар халкының этник төркемнәре һәм диалектлары, төрки телләр, татар теле, татар язуы, татар халкының рухи, әхлакый, мәдәни мирасы турында мәгълүмат бирү;

●татар телен иҗтимагый күренеш буларак аңлау, тел нормаларын саклап, тормышның төрле ситуацияләренә бәйле рәвештә тел чараларын дөрес кулланып, аралаша-аңлаша белү;

●тел берәмлекләрен танып, аларны тикшерә, рус теле белән чагыштыра алу һәм аралашуда урынлы куллану күнекмәләрен камилләштерү.

**Укыту предметының укыту планында тоткан урыны**

Гомуми төп һәм урта белем бирү мәктәбенең 6 нчы сыйныфында ана теленнән белемнәр киңәйтелә. 5 нче сыйныфта башлангыч сыйныфлардагы укыту предметының эчтәлеге тирәнәйтелеп кабатлана. 6 нчы сыйныфта ФДББСның базис укыту планы буенча татар теле укытуга сәгатьләр саны 1 дәрес киңәйтеп өйрәнүгә бирелү сәбәпле, түбәндәгечә каралган: атнага 4 сәгать. Барысы 140 сәгать.

**Белем дәрәҗәсенә таләпләр**

Гомуми төп һәм урта белем бирү мәктәбенең 6 нчы сыйныфында татар теле предметын өйрәтү тел берәмлекләрен таный, аңлый һәм анализлый белү күнекмәләре белән бергә, сөйләм культурасын үстерүне, төрле типтагы һәм жанрдагы мәгълүматны үзләштерүне, аларны, сөйләм ситуациясенә һәм төренә карап, дөрес, төгәл итеп башкаларга җиткерә алуны, татар теленең әдәби һәм сөйләм әдәбе нормаларын күз алдында тота.

**Шәхес буларак үсешне күрсәтүче нәтиҗәләр**:

- татар теленең татар халкы өчен төп милли-мәдәни кыйммәт булуын, ана телендә шәхеснең әхлакый, рухи һәм иҗади яктан формалашудагы ролен аңлау;
- туган телгә мәхәббәт һәм аның белән горурлану хисләре тәрбияләү, туган телне саклау һәм үстерү өлкәсендә эшләргә теләк, омтылыш уяту;
- туган телдә аралашу, үз фикереңне һәм хисләреңне төгәл, анык, күпьяклы итеп белдерү өчен кирәкле булган сүзлек составын һәм грамматик, стилистик чараларны белү;
- аралашу төренә һәм ситуациясенә бәйле сөйләмне куллана һәм үзара бәйли белү;
- иптәшләренең сөйләменә игътибар итү, үзеңнең сөйләмеңә күзәтеп бәя бирү, хаталарны төзәтү, бәхәстә катнашу, төрле дәлилләр кулланып, тема буенча фикер алышу.

**Предметны үзләштерү барышында ирешәчәк нәтиҗәләр:**

- сөйләмиятнең барлык төрләрен (тыңлау, аңлау, уку, язу) үзләштерү: язма һәм сөйләм теленә караган мәгълүматның темасын, төп һәм өстәмә фикерен аңлау; төрле стильгә һәм жанрга караган текстларны дөрес уку һәм аңлау; төрле чыганаклардан мәгълүмат туплый белү; сүзлекләрдән һәм электрон чаралардан дөрес файдалана белү; аерым бер темага караган материалны туплый, анализлый, эшкәртә һәм үзгәртә белү;
- татар теленең төп функцияләрен, татар теленең башка төрки телләр арасында тоткан урынын, телнең мәдәният, җәмгыять белән тыгыз бәйләнешен аңлау;
- туган тел турындагы фәнни белемнәрнең нигезен булдыру, тел катламнарының, ярусларының үзара бәйләнешен һәм мөнәсәбәтен аңлау;
- тел белеменең төп төшенчәләрен үзләштерү, аның тармаклары турында мәгълүмат булдыру; тел һәм сөйләм, сөйләм төрләре, аралашу ситуацияләре; сөйләм теле, функциональ стильләр, матур әдәбият теле; текст һәм аның төрләре; телнең төп берәмлекләре, аларның аермалы билгеләрен, сөйләмдә кулланылу үзенчәлекләрен белү;
- телнең төп стилистик чараларын, телнең әдәби нормаларын, сөйләм әдәбе нормаларын белү, аларны сөйләмдә дөрес кулланырга өйрәнү;
- тел һәм сөйләм берәмлекләрен аера һәм анализлый белү; тел һәм стилистик чараларның кулланылышына бәйле рәвештә сөйләм төрләрен аера һәм чагыштыра белү;

- телнең сәнгати чараларын аеру, аларның эстетик функцияләрен белү.

**Метапредмет нәтиҗәләре**:

-татар теленең башка фәннәрне өйрәнү һәм белем алу чарасы икәнен аңлау;

-татар телен әдәбият белән бәйләп, тел чараларының матур әдәбият әсәрләрендәге тәэсир көчен, сәнгатьлелеген булдыруда ролен ачыклау; чор әдәбиятына хас тел-сурәтләү чараларының үзенчәлекләрен ачу;

-телне әдәбият белән бәйләп, укыган яки тыңлаган әсәрнең эчтәлеген, планын, конспектын, резюмесын логик эзлекле итеп язарга, сөйләргә өйрәтү;

-телне мәдәният белән бәйләп, татар теленең байлыгына һәм матурлыгына хөрмәт, зәвык тәрбияләү;

-татар телен рус теле белән бәйләп, телләр һәм халыклар арасындагы уртак хәзинә – рухи кыйммәтләргә ихтирам, башка милләт вәкилләренә карата түземле-ихтирамлы мөнәсәбәт тәрбияләү; телләрнең үзара бәйләныш-мөнәсәбәтләрен, шул мөнәсәбәтләр нәтиҗәсендә уртак төшенчәләр һәм тел берәмлекләре барлыкка килүне аңлату;

-рус һәм чит телләр, әдәбиятлар белән бәйләп, татар теленең милли-мәдәни үзенчәлекләрен өйрәтү, алган белемнәрне төрле тел күренешләрен аңлатуда куллану;

-телне тарих, җәмгыять белеме фәннәре белән бәйләп, дөнья, кешелек җәмгыяте, аның үсеше турында күзаллау формалаштыру, җәмгыять үсешенең телгә турыдан-туры мөнәсәбәте булуын җиткерү;

-татар теле дәресләрендә алган белем һәм күнекмәләрне телнең кеше һәм җәмгыять тормышында тоткан урынын аңларга ярдәм итү; сөйләмне дөрес куллана, бәяли белергә, үз фикереңнең уңай һәм тискәре якларын аңларга, камилләштерергә өйрәтү;

-әдәби әсәрләрнең теле белән эшләгәндә, татар теле – бәйләүче чараларга бик бай тел, шул чаралар системасын, алар белдергән мәгънәләрне нәтиҗәлерәк үзләштерү максатыннан, стиль мөмкинлекләрен дә исәпкә алып, фикерне төгәл бирердәй сүзтезмә һәм җөмләләрне телебез хәзинәсеннән сайлап ала белү.

**Эш программасының эчтәлеге**

| **Темалар** | **Сәгать саны** |
|---|---|
| Татар әдәби теле. | 1 |
| Алдагы сыйныфларда үткәннәрне кабатлау. Җөмлә кисәкләре. Ясалышы ягыннан сүз төрләре. Морфология | 5 |
| Исем. Исемнәрнең мәгънә төркемчәләре | 2 |
| Исемнәрнең килешләр белән төрләнеше | 3 |
| Б.С.Ү.Белдерү язу | 1 |
| Исемнәрнең тартым белән төрләнеше | 1 |
| Тартымлы исемнәрнең килеш белән төрләнүе. | 2 |
| Исемнәрнең ясалышы | 1 |
| Исем сүз төркемен гомумиләштереп кабатлау | 2 |
| Фигыль турында төшенчә. Фигыльнең башлангыч формасы. Барлык-юклык төре. | 1 |
| Фигыльнең зат-сан белән төрләнеше. | 2 |
| Фигыль юнәлешләре | 2 |
| Фигыль төркемчәләре турында төшенчә. Боерык фигыль, аның мәгънәсе, зат-сан белән төрләнеше. | 2 |

| | |
|---|---|
| Боерык фигыль. | 2 |
| Теләк фигыль. | 2 |
| Хикәя фигыль. Хәзерге заман хикәя фигыльләр, аларның мәгънәләре һәм зат-сан белән төрләнеше. | 2 |
| Үткән заман хикәя фигыльләр. Аларның мәгънәләре , формалары һәм зат-сан белән төрләнеше | 2 |
| Киләчәк заман хикәя фигыльләр. Аларның мәгънәләре һәм зат-сан белән төрләнеше, дөрес язылышы | 2 |
| Шарт фигыль, аның мәгънәсе, формалары, зат-сан белән төрләнеше һәм җөмләдә кулллланылышы. | 1 |
| Затланышсыз фигыльләр.  Сыйфат фигыль, аның мәгънәсе, сыйфат һәм фигыль уртаклыгы. | 1 |
| Сыйфат фигыльнең заман формалары, аларның хикәя фигыль белән уртаклыгы | 3 |
| Хәл фигыль, аның мәгънәсе, төрләре, җөмләдә кулланылышы һәм дөрес язылышы. | 2 |
| Исем фигыль, аның мәгънәсе, исемгә әйләнүе. | 2 |
| Инфинитив, аның җөмләдә кулланылышы һәм дөрес язылышы | 2 |
| Ярдәмче фигыльләр һәм аларның җөмләдә кулланылыш. | 1 |
| Мөстәкыйль фигыльләрнең ярдәмче фигыль ролендә йөрүе. | 2 |
| Фигыльләрнең ясалыш ягыннан төрләре. | 2 |
| Фигыльнең  җөмләдә кулланылышы | 2 |
| Фигыльне гомумиләштереп кабатлау, аларга морфологик анализ ясау. | 3 |
| Сыйфат турында төшенчә. Сыйфат дәрәҗәләре. Асыл һәм нисби сыйфатлар | 2 |
| Сыйфатларның исемләшүе һәм җөмләдә кулланылышы | 2 |
| Сыйфатларның ясалышы һәм сыйфат ясагыч кушымчалар. | 2 |
| Сыйфатларны гомумиләштереп кабатлау, аларга морфологик анализ ясау | 2 |
| Рәвеш турында гомуми төшенчә,.рәвеш төркемчәләре | 2 |
| Рәвешләрнең җөмләдә кулланылышы | 2 |
| Рәвеш дәрәҗәләре | 1 |
| Рәвешләрнең ясалышы ягыннан төрләре һәм дөрес язылышы. | 2 |
| Рәвешне гомумиләштереп кабатлау,аларга морфологик анализ ясау | 2 |
| Сан турында гомуми төшенчә. Гарәп һәм рим цифрлары. | 2 |
| Ясалышы ягыннан сан төрләре һәм аларның дөрес язылышы. | 1 |
| Сан төркемчәләре, аларның мәгънәләре һәм кулланылышы. | 2 |
| Саннарны гомумиләштереп кабатлау, аларга морфологик анализ ясау. | 2 |
| Алмашлык турында гомуми төшенчә. Алмашлык төркемчәләре. | 2 |
| Зат алмашлыклары, аларның килеш белән төрләнеше | 1 |

| | |
|---|---|
| Аваз ияртемнәре турында гомуми төшенчә. Аваз ияртемнәреннән ясалган сүзләр. Аваз ияртемнәренә морфологик анализ | 2 |
| Хәбәрлек сүзләр турында гомуми төшенчә. Хәбәрлек сүзләрне морфологик яктан тикшерү. | 2 |
| Бәйлек турында төшенчә | 1 |
| Бәйлекләрнең төркемчәләре. | 2 |
| Бәйлек сүзләр, аларның кулланылу үзенчәлекләре. | 2 |
| Теркәгеч турында гомуми төшенчә. | 1 |
| Теркәгечләрнең төркемчәләре | 2 |
| Теркәгечләрнең дөрес язылышы | 2 |
| Модаль сүз төркеме турында төшенчә. | 1 |
| Кисәкчә турында төшенчә. | 1 |
| Кисәкчәләрнең төркемчәләре | 2 |
| Кисәкчәләрнең дөрес язылышы. | 2 |
| Модаль сүзләр турында гомуми төшенчә, аларның мәгънәләре һәм җөмләдә кулланылу үзенчәлекләре. | 2 |
| Ымлыклар турында гомуми төшенчә. Ымлыкларның дөрес язылышы, алар янында тыныш билгеләре | 2 |
| Морфология буенча үткәннәрне гомумиләштереп кабатлау | 4 |
| Язма эшләр. Диктант. Изложение. Сочинение. Эш кәгазе. Сочинение, изложениене тикшерү, анализлау. | 30 |

«Сарман урта гомумбелем бирү мәктәбе» муниципаль белем бирү бюджет учреждениесенең «Укыту предметы, курсы, дисциплинасының эш программасы турында»гы 29 нчы август, 2016 нчы елда педсоветта каралган(беркетмә № 1) һәм мәктәп директоры тарафыннан 2016 нчы елның 29 нчы августында чыккан 109 нчы санлы приказы белән расланган нигезнамәсенең 5 пунктына таянып, дәресләр бәйрәм көннәренә туры килү сәбәпле, 6 нчы А сыйныфында дәресләр сәгатьләрне берләштерү исәбенә программа үтәлә

**Укыту-методик комплекты**


1. Дәреслек: 6 нчы сыйныф өчен Ф.Ю.Юсупов, Ч.М.Харисова, Р.Р.Сәйфетдинов;-Казан:Татар.кит.нәшр.,2014.
2. «Татар телендә урта гомуми белем бирү мәктәпләре өчен татар теле һәм әдәбиятыннан үрнәк программалар:1-11”- Казан: Татар.кит.нәшр.,2011.
3. Урта мәктәп һәм гимназияләрдә татар телен укыту методикасы (Ф.С.Вәлиев, Г.Р.Саттаров. – Казан. “Раннур”, 2000)
5. Хәзерге татар әдәби теле. (Ф.С.Сафиуллина, М.З.Зәкиев. Казан, “Мәгариф”, 2005
6. В.Максимов, Г.Ә.Нәбиуллина. Татар телендә укытучылар өчен кулланма. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2014
7. Диктантлар җыентыгы (төрле авторлар).
8. Изложениеләр җыентыгы (төрле авторлар).
9. Вәлиева Ф.С., Саттаров Г.Ф. Урта мәктәп һәм гимназияләрдә татар телен укыту методикасы, К..: Раннур н-ты, 2000.


**Интернет-ресурслар**

1. http:// www.mon.gov/ru РФ Мәгариф һәм фән министрлыгы
2. http:// www.tatedu.ru ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы
3. http:// www.edu.kzn.ru ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы Белем порталы
4. http:// tataroved.ru Татар тарихы: төрки- татар дөньясы
   tugantelem.narod.ru,
   qushlawich.ru,
   gzalilova.narod.ru

**Календарь - тематик план**

| № | Дәрес темасы | Укучыларның эшчәнлеге төрләре | Үткәрү вакыты | |
|---|---|---|---|---|
| | | | План | Факт. |
| 1 | Татар әдәби теле. | Тел гыйлеменең тел төзелешен, кулланылышын һәм үсешен өйрәнүе | 02.09 | |
| 2 | Алдагы сыйныф<br>ларда үткәннәрне кабатлау. Җөмлә кисәкләре | Ия белән хәбәрне һәм җөмләнең башка кисәкләрен табу. | 04.09 | |
| 3-5 | Ясалышы ягыннан сүз төрләре | Сүзләрне морфемаларга таркатып, ясалыш төрен билгеләү. | 06.09<br>08.09<br>9.09 | |
| 6 | Морфология | Тел гыйлеменең морфология бүлеге өйрәнү предметын искә төшерү | 11.09 | |
| 7 | Үткәннәрне кабатлау буенча тикшерү диктанты(кереш диктант) | Алдагы сыйныфта үзләштерүне тикшерү максатында | 13.09 | |
| 8 | Хаталарны төзәтү эше | Дөрес язу күнекмәләрен ныгыту,камилләштерү | 15.09 | |
| 9 | Җәйге хатирәләр (сочинение) | Җәйге хатирәләргә таянып, язма сөйләм оештыру. | 16.09 | |
| 10-11 | Исем. Исемнәрнең мәгънә төркемчәләре | Предметларны һәм затларны белдерә торган сүзләр. Ялгызлык, уртаклык исемнәрне аера белү | 18.09<br>20.09 | |
| 12-13-14 | Исемнәрнең килешләр белән төрләнеше | Килеш кушымчаларының исемнәргә ялгану үзенчәлеге. Б, в, г, д тартыкларына беткән исемнәрне килешләр белән дөрес төрләндерә белү. Исемнәрне килешләрдә төрләндереп, шушы грамматик категориянең үзенчәлекләрен барлау. | 22.09<br>23.09<br>25.09 | |
| 15 | Б.С.Ү.Белдерү  язу | Белдерү язу тәртибен өйрәнү | 27.09 | |
| 16- | Исемнәрнең тартым белән төрләнеше | Исемнәрне тартым белән төрләндереп, шушы грамматик категориянең үзенчәлекләрен билгеләү. Җөмләләрдәге исемнәрне табып, килешләрен билгеләү. Исем сүз төркемен тартым белән төрләндереп, җөмләдә дөрес куллана белү | 29.09 | |
| 17-18 | Тартымлы исемнәрнең килеш белән төрләнүе. | Тартымлы исемнәрне килешләрдә төрләндерү, тартымсыз исемнәрнең килеш белән төрләнешендәге аерманы табу. Тартымлы исемнәрне килешләрдә дөрес итеп төрләндерә белү. | 30.09<br>02.10 | |
| 19 | Исемнәрнең ясалышы | Исемнәрнең ясалыш ягыннан төрләрен,  ясалыш ысулларын билгели белү., Исемгә тулы морфологик анализ ясый белү, исемне сөйләмдә тиешле грамматик категориядә куллана белү | 04.10 | |
| 20-21 | Исем сүз төркемен гомумиләштереп  кабатлау | Исемнәрнең җөмләдәге вазифасын билгели белү Исемнәргә тулы морфологк анализ ясый белү исемне сөйләмдә тиешле грамматик категориядә куллана белү | 06.10<br>7.10 | |
| 22-23 | “Исем” темасын ныгыту буенча күрмә изложение (59 нчы кунегу) | Гади план  нигезендә фикерне эзлекле язу. Фикерне эзлекле язу күнекмәләре булдыру | 9.10<br>11.10 | |
| 24 | Хаталарны төзәтү эше | Изложениедәге хаталарны туплый, анализлый, эшкәртә, төзәтә белү | 13.10 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 25-26 | Сыйфат турында төшенчә. Сыйфат дәрәҗәләре. Асыл һәм нисби сыйфатлар | Күнегүләр эшләү | 14/10<br>16/10 | |
| 27-28 | Сыйфатларның исемләшүе һәм җөмләдә кулланылышы | Күнегүләр эшләү | 18/10<br>20/10 | |
| 29-30 | Сыйфатларның ясалышы һәм сыйфат ясагыч кушымчалар. | Күнегүләр эшләү | 21/10<br>23/10 | |
| 31-32 | Сыйфатларны гомумиләштереп кабатлау, аларга морфологик анализ ясау | Күнегүләр эшләү, морфологик анализ ясау | 25/10<br>27/10 | |
| 33 | Контроль диктант | Дөрес язу күнекмәләрен ныгыту,камилләштерү | 28/10 | |
| **34** | Хаталарны төзәтү эше | Диктанттагы хаталарны туплый, анализлый, эшкәртә, төзәтә белү | 6/11 | |
| 35-36 | Рәвеш турында гомуми төшенчә,.рәвеш төркемчәләре | Күнегүләр эшләү | 10.02<br>12.02 | |
| 37-38 | Рәвешләрнең җөмләдә кулланылышы | Күнегүләр эшләү | 14.02<br>16.02 | |
| 39 | Рәвеш дәрәҗәләре | Күнегүләр эшләү | 17.02 | |
| 40-41 | Рәвешләрнең ясалышы ягыннан төрләре һәм дөрес язылышы. | Күнегүләр эшләү | 19.02<br>21.02 | |
| 42-43 | Рәвешне гомумиләштереп кабатлау,аларга морфологик анализ ясау | Күнегүләр эшләү ,морфологик анализ ясау | 23.02<br>24.02 | |
| 44-45 | Контроль изложение. | Фикерне эзлекле язу күнекмәләрен ныгыту, камилләштерү | 26.02<br>28/02 | |
| 46 | Хаталарны төзәтү эше | Фикерне эзлекле язу күнекмәләрен ныгыту, камилләштерү | 02.03 | |
| 47-48 | Сан турында гомуми төшенчә. Гарәп һәм рим цифрлары. | Күнегүләр эшләү | 03.03<br>05.03 | |
| 49 | Ясалышы ягыннан сан төрләре һәм аларның дөрес язылышы. | Күнегүләр эшләү | 7.03 | |
| 50-51 | Сан төркемчәләре, аларның мәгънәләре һәм кулланылышы. | Күнегүләр эшләү | 9.03<br>10.03 | |
| 52-53 | Саннарны гомумиләштереп кабатлау, аларга морфологик анализ ясау. | Күнегүләр эшләү ,морфологик анализ ясау | 12.03<br>14.03 | |
| 54 | Диктант. | Дөрес язу күнекмәләрен ныгыту,камилләш терү | 16.03 | |
| 55 | Хаталарны  төзәтү эше | Диктанттагы хаталарны туплый, анализлый, эшкәртә, төзәтә белү | 17.03 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 56-57 | Алмашлык турында гомуми төшенчә. Алмашлык төркемчәләре. | Күнегүләр эшләү | 19.03<br>21.03 | |
| 58 | Зат алмашлыклары, аларның килеш белән төрләнеше | Күнегүләр эшләү | 23.03 | |
| 59-60 | Сочинение | Алган белемгә таянып, язма сөйләм оештыру. | 24/03<br>04.04 | |
| 61 | Хаталарны төзәтү эше | Сочинениедәге хаталарны туплый, анализлый, эшкәртә, төзәтә белү | 6.04 | |
| 62 | Фигыль турында төшенчә. Фигыльнең башлангыч формасы. Барлык-юклык төре. | Фигыльләрнең мәгънә буенча төрләргә аера белү. Фигыльләрнең җөмләдәге рольләрен аңлау, дөрес язу һәм сөйләмдә дөрес куллану. | 8/11 | |
| 63-64 | Боерык фигыль. | Боерык фигыль – фигыльнең нигезе. | 10/11<br>11/11 | |
| 65-66 | Теләк фигыль. | Теләк фигыльнең үзенчәлекләре | 8.11<br>10.11 | |
| 67-68 | Хикәя фигыль. Хәзерге заман хикәя фигыльләр, аларның мәгънәләре һәм зат-сан белән төрләнеше. | Грамматик биремнәр ярдәмендә хәзерге заман хикәя фигыль формасын ясалышын өйрәнү Фигыльләрне хәзерге заманда зат-сан белән төрләндерү Хәзерге заман хикәя фигыль формасын сөйләмдә урынлы. куллана белү. | 11.11<br>13.11 | |
| 69-70 | Үткән заман хикәя фигыльләр. Аларның мәгънәләре , формалары һәм зат-сан белән төрләнеше | Аңлату, әңгәмә. Күнегүләр эшләү | 13.11<br>15.11 | |
| 71-72 | Киләчәк заман хикәя фигыльләр. Аларның мәгънәләре һәм зат-сан белән төрләнеше, дөрес язылышы | Аңлату, әңгәмә. Күнегүләр эшләү | 17.11<br>18.11 | |
| 73 | Диктант. | Дөрес язу күнекмәләрен ныгыту,камилләштерү | 20.11 | |
| 74 | Хаталарны төзәтү эше | Диктанттагы хаталарны туплый, анализлый, эшкәртә, төзәтә белү | 22.11 | |
| 75 | Шарт фигыль, аның мәгънәсе, формалары, зат-сан белән төрләнеше һәм җөмләдә кулллланылышы. | Аңлату, әңгәмә. Күнегүләр эшләү | 24.11 | |
| 76 | Затланышсыз фигыльләр. Сыйфат фигыль, аның мәгънәсе, сыйфат һәм фигыль уртаклыгы. | Аңлату, әңгәмә. Күнегүләр эшләү | 25.11 | |
| 77-78 | Сочинение. | Алган белемгә таянып, язма сөйләм оештыру. | 27.11<br>29.11 | |
| 79-81 | Сыйфат фигыльнең заман формалары, аларның хикәя фигыль | Аңлату, әңгәмә. Күнегүләр эшләү | 01.12<br>02.12 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | белән уртаклыгы | | 04.12 | |
| 82-83 | Хәл фигыль, аның мәгънәсе, төрләре, җөмләдә кулланылышы һәм дөрес язылышы. | Аңлату, әңгәмә. Күнегүләр эшләү | 06.12<br>8.12 | |
| 84-85 | Исем фигыль, аның мәгънәсе, исемгә әйләнүе. | Аңлату, әңгәмә. Күнегүләр эшләү | 9.12<br>11.12 | |
| 86-87 | Инфинитив, аның җөмләдә кулланылышы һәм дөрес язылышы | Аңлату, әңгәмә. Күнегүләр эшләү | 13.12<br>15.12 | |
| 88 | Ярдәмче фигыльләр һәм аларның җөмләдә кулланылы | Аңлату, әңгәмә. Күнегүләр эшләү | 16.12 | |
| 89-90 | Мөстәкыйль фигыльләрнең ярдәмче фигыль ролендә йөрүе. | Аңлату, әңгәмә. Күнегүләр эшләү | 18.12<br>20.12 | |
| 91 | Контроль диктант. | Дөрес язу күнекмәләрен ныгыту,камилләштерү | 22.12 | |
| 92 | Фигыльләрнең ясалыш ягыннан төрләре. | Күнегүләр эшләү | 23/12 | |
| 93 | Фигыльнең җөмләдә кулланылышы | Күнегүләр эшләү | 8.01 | |
| 94-98 | Фигыльне гомумиләштереп кабатлау, аларга морфологик анализ ясау. | Күнегүләр эшләү, морфологик анализ ясау | 10.01<br>12.01<br>13.01<br>15.01<br>17.01 | |
| 99-100 | Изложение. | Фикерне эзлекле язу күнекмәләрен кабатлау, ныгыту | 19.01<br>20.01 | |
| **101** | Хаталарны төзәтү эше | Изложениедәге хаталарны туплый, анализлый, эшкәртә, төзәтә белү | 22.01 | |
| 108-109 | Аваз ияртемнәре турында гомуми төшенчә. Аваз ияртемнәреннән ясалган сүзләр. Аваз ияртемнәренә морфологик анализ | Күнегүләр эшләү | 7.04<br>9.04 | |
| 110-111 | Хәбәрлек сүзләр турында гомуми төшенчә. Хәбәрлек сүзләрне морфологик яктан тикшерү. | Күнегүләр эшләү ,морфологик анализ ясау | 11.04<br>13.04 | |
| 112 | Бәйлек турында төшенчә | Күнегүләр эшләү | 14.04 | |
| 113-114 | Бәйлекләрнең төркемчәләре. | Күнегүләр эшләү | 16.04<br>18.04 | |
| 115-116 | Бәйлек сүзләр, аларның кулланылу үзенчәлекләре. | Күнегүләр эшләү | 20.04<br>21.04 | |
| 117 | Теркәгеч турында гомуми төшенчә. | Күнегүләр эшләү | 23.04 | |
| 118- | Теркәгечләрнең төркемчәләре | Күнегүләр эшләү | 25.04 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 119 | | | 27.04 | |
| 120-121 | Теркәгечләрнең дөрес язылышы | Күнегүләр эшләү | 28.04<br>30/04 | |
| 122 | Модаль сүз төркеме турында төшенчә. | Күнегүләр эшләү | 02.05 | |
| 123 | Кисәкчә турында төшенчә. | Аерым сүзләрнең яки җөмләләрнең мәгънәләренә өстәмә төсмер бирә торган сүз төркеменең **кисәкчә** дип аталуы. | 04.05 | |
| 124-125 | Кисәкчәләрнең төркемчәләре | Аерым сүзнең һәм җөмләнең мәгънәсенә нинди өстәмә төсмер бирүенә карап, кисәкчәләрнең 8 төркемчәгә (көчәйткечләр, чикләүчеләр, сорауны белдерүчеләр, якынлык-ераклык яки тизлекне белдерүчеләр, раслау ныгытучылар, билгесезлек, икеләнүне белдерүчеләр, үтенү һәм теләкне белдерүчеләр, инкарь итүне һәм юклыкны белдерүчеләр) бүленүе. | 05.05<br>07.05 | |
| 126-127 | Кисәкчәләрнең дөрес язылышы. | Кисәкчәләрнең дөрес язылышын үзләштерү. (Көчәйткеч кисәкчәләрдән: сүзнең беренче иҗегенә җайлаштырылган артыклык дәрә-җәсе ясый торган кисәкчәләр сызыкча аша языла; сүзнең беренче иҗеге белән уртаклыгы булмаган кисәкчәләр аерым языла. Һич кисәкчәсе юклык алмашлыгы ясаганда кушылып языла. Башка сүз белән килгәндә һич кисәкчәсе аерым языла. Сүз ахырында килә торган -мы, -ме, -мыни, -мени, -дыр, -дер, -тыр, -тер, -чы, -че, -са-на, -сәнә кисәкчәләре кушылып языла. Сүз яки җөмлә соңында килгән да, дә, та, тә, гына, генә, ук, үк, ла, лә, лабаса, ләбаса, бит, ич, түгел кисәкчәләре аерым языла. | 9.05<br>11.05 | |
| 128-129 | Изложение | Фикерне эзлекле язу күнекмәләре камилләштерү | 12.05<br>14.05 | |
| 130 | Хаталарны төзәтү эше | Изложениедәге хаталарны туплый, анализлый, эшкәртә, төзәтә белү | 16.05 | |
| 131-132 | Модаль сүзләр турында гомуми төшенчә, аларның мәгънәләре һәм җөмләдә кулланылу үзенчәлекләре. | Мод. сүзләр турында төшенчә бирү, аларны барлау, сөйләмгә кертү. | 18.05<br>19.05 | |
| 133 | Контроль диктант | Дөрес язу күнекмәләрен ныгыту,камилләштерү, тикшерү дәресе | 21.05 | |
| 134 | Хаталарны төзәтү эше | Диктанттагы хаталарны туплый, анализлый, эшкәртә, төзәтә белү | 23.05 | |
| 135-136 | Ымлыклар турында гомуми төшенчә. Ымлыкларның дөрес язылышы, алар янында тыныш билгеләре | Ымлыкларны сөйләмдә актив куллана белү. | 25.05<br>26/05 | |
| 137-140 | Морфология буенча үткәннәрне гомумиләштереп кабатлау | Ел буена алган белемнәрне бер системага салып кабатлау. | 28/05<br>30.05 | |